Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 5**

Күки авылы 2019 елның 30 апреле

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге “Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәрне раслау турында” 711/пр номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проектын 1 номерлы кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә һәм ачык (гавами) тыңлауларга чыгарырга.

2. Раcларга:

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча 2 номерлы кушымта нигезендә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибен;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча 3 кушымта нигезендә ачык (гавами) тыңлаулар уздыру Тәртибен.

3. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта оештыру комитеты төзергә (алга таба – оештыру комитеты):

Бәдретдинов Алберт Миннехан – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башлыгы, оештыру комитеты рәисе;

Заһидуллин Илгиз Габдрәүф улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы утырышчысы, оештыру комитеты әгъзасы;

Фасхиев Марат Ахкам улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы утырышчысы, оештыру комитеты әгъзасы.

4. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык (гавами) тыңлауларны 2019 елның 31 мае көнне 11.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт.

5. Оештыру комитетына “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты ачык тыңлауларда әйтелгән һәм аның буенча фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм икенче укылышта кабул итү өчен “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы каравына кертүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ндаурнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советының
2019 елның 30 апрелендәге
5 номерлы карарына
кушымта №1

**“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының 2018 елның 30 ноябрендәге “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 92-ТРЗ номерлы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге “Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәрне раслау турында” 711/пр номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен карап, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 апрелендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге

Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) II Бүлек. Түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“каты коммуналь калдыклар (ККК) – физик затлар куллану процессында торак урыннарда барлыкка килә торган калдыклар, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында физик затлар тарафыннан аларны торак урыннарда куллану процессында үзләренең куллану үзлекләрен югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга шулай ук юридик затлар, шәхси эшкуарлар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган һәм физик затлар куллану процессында торак урыннарда барлыкка килә торган калдыклар составы буенча охшаш калдыклар керә;".

“җитештерү һәм куллану калдыклары – әлеге Федераль закон нигезендә юкка чыгарыла торган яисә бетерелергә тиешле җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү процессында яисә куллану процессында барлыкка килгән матдәләр яисә әйберләр;”.

“контейнер – каты коммуналь калдыкларны, эре габаритлы калдыклардан тыш, җыю өчен билгеләнгән чүп-чар җыентыгы;”.

“каты коммуналь калдыкларны чыгару – каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарыннан алып аларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү өчен файдаланыла торган объектларга кадәр ташу (илтү)”;.

“арборицидлар – чүп-чар (файдасыз) агач-куак үсемлекләренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;”.

“Сосновский балтырганы – үләнчел эре үсемлек, чатырсыманнар гаиләсеннән булган балтырган.Үсемлек озак вакыт төзәлми торган көчле пешүләр китереп чыгарырга сәләтле;”.

“гербицидлар – үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр;".

1.2) II бүлекнең 42 абзацы. Түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“орынып торган (янәшә) территория – бинага, каралтыга, корылмага, җир кишәрлегенә, әгәр андый җир кишәрлеге рөхсәт ителгән төргә, функциональ билгеләнешкә, мәйданга һәм муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү Кагыйдәләре белән билгеләнгән бүтән факторларга бәйле рәвештә оештырылган очракта тоташкан гомуми файдаланудагы территория.

Орынып торган (янәшә) территорияләрне раслау һәм аларның чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы тарафыннан орынып торган (янәшә) территорияләр чикләре схемасын раслау юлы белән гамәлгә ашырыла”.

1.3) 4.6. пунктның 4.6.1.7. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.6.1.7. Каты көнкүреш һәм эре габаритлы калдыкларны чыгаруны гамәлгә ашыралар:

- күпфатирлы йортлардан – билгеләнгән тәртиптә калдыклар белән мөгамәлә өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы I – IV класс хәтәрлектәге

калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиясе булган юридик һәм физик затлар;

-индивидуаль торак йортлардан – торак йортларның ияләре мөстәкыйль рәвештә яисә билгеләнгән тәртиптә калдыклар белән мөгамәлә өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы I – IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиясе булган юридик һәм физик затлар белән шартнамә буенча;

- гомуми файдаланудагы территорияләрдән һәм калдыкларның вакытлыча туплану урыннарыннан – билгеләнгән тәртиптә калдыклар белән мөгамәлә өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы I – IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиясе булган юридик һәм физик затлар;

- коммуналь калдыкларны һәм чүп-чарны сәүдә һәм җәмәгать туклануы, мәдәният оешмаларыннан, балалар һәм дәвалау йортларыннан чыгару күрсәтелгән оешмалар тарафыннан, шулай ук башка калдыклар булдыручылар тарафыннан I – IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиясе булган махсуслашкан оешмалар белән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла;

-башка территорияләрдән – индивидуаль эшкуарлар, юридик затлар, әлеге территорияләрнең хокукый ияләре табигатьне саклау һәм санитария таләпләрен үтәү шартында мөстәкыйль рәвештә яисә билгеләнгән тәртиптә калдыклар белән мөгамәлә өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы I – IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиясе булган юридик яки физик зат белән шартнамә буенча.

ККК һәм эре габаритлы, төзелеш чүп-чарын җыю һәм чыгару гамәлдәге норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә контейнерлар белән яки тарасыз система буенча гамәлгә ашырыла. ККК туплануга карап системалы рәвештә чыгарыла, тик тәүлеккә бер мәртәбәдән дә сирәк түгел – тыш һавасының температурасы елның җылы вакытында +5 град. С һәм аннан югары булганда һәм салкын чорда ( температура -5 град. һәм аннан түбән булганда) өч көнгә бер тапкырдан да ким түгел. Шуның белән бергә чыгаруның периодиклыгына бәйсез рәвештә контейнерларның тулып артуы рөхсәт ителми.Эре габаритлы һәм төзелеш чүп-чарын контейнерлар мәйданчыкларыннан озату туплануга карап, әмма атнага бер тапкырдан да ким түгел.”.

1.4) IV бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.6.11 пункты белән тулыландырырга:

"4.6.11 Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар

Җир кишәрлекләренең хокукый ияләре үз милекләрендәге, биләмәләрендәге яки файдаланудагы җир кишәрлекләреннән Сосновский балтырганын бетерү буенча чаралар күрергә бурычлы. Сосновский балтырганын бетерү буенча чаралар ул чәчәккә бөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.

Сосновский балтырганын бетерү буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелергә мөмкин:

химик юл белән – үсеп чыга торган урыннарына гербицидлар һәм (яки) арборицидлар сиптерү;

механик юл белән – чабу, коры үсемлекләрне җыеп алу, тамыр системасын казып алу;

агротехник юл белән – туфрак эшкәртү, күпьеллык үлән чәчү.”.

Җир кишәрлекләреннән Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар күрмәү кисәтүгә яки административ штраф салуга сәбәпче була.”.

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советының
2019 елның 30 апрелендәге
5 номерлы карарына
кушымта № 2

**“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибе**

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советына кертелә:

| № п/п | Маддә, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес (почта) буенча юллана: 422669, ТР, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт яисә (88-43-61)30581 факсы буенча.

Тәкъдимнәр “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының карар проекты игълан ителгән көннән алып 2019 елның 29 маена чаклы эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422669, ТР, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт яисә (88-43-61) 30581 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәг.кә чаклы ачык тыңлаулар үткәрелү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителәләр.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитетына тапшырылалар.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советының
2019 елның 30 апрелендәге
5 номерлы карарына
кушымта №3

**“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар уздыру Тәртибе**

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар (алга таба – ачык (гавами) тыңлаулар, тиңдәшле рәвештә карар проекты) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 19 маддәсе һәм әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

2. Үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар булып язма рәвештә үзләренең гаризаларын ачык тыңлаулар үткәрелү датасына хәтле җиде көннән дә соңга калмыйча җирлек Советына биргән җирлектә яшәүчеләр тора.

3. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия булмый гына катнашучылар булып җирлекнең һәммә кызыксынучы кешесе торырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 1 сәг. алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда җирлек Башлыгы яки аның кушуы буенча авыл җирлегенең башка вазифаи заты рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул залда булучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе хакында мәгълүмат ирештерә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында секретариат сайлана.

8. Төп доклад белән “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты рәисе чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларның чыгыш ясау хокукына ия катнашучылары гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырылалар.

10.Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүченең рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан артыкка түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хаклы түгел.

13. Ачык тыңлауларны үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында рәислек итүче аларны залдан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хаклы.

15. Чыгышлар төгәлләнгәннән соң рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәр, киңәшләрне аныклау өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык замечание һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә җирлек Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) оештыру комитеты тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) халыкка игълан ителергә тиешле.

19.Ачык тыңлауларны үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов